ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

17.02.2017 № 018-од

г. Казань

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге № 172-ФЗ Федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге № 96 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.12.2009 № 883 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис

И.Х.Әюпова

Татарстан Республикасы
Архив эше буенча дэүлэт комитеты
№ 018 -од боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына (алга таба – актлар) һәм норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан эшләнә торган актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедурасын билгели, моңа Дәүләт комитеты актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза да керә.

1.2. Актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза аларга хокукый экспертиза уздырганда гамәлгә ашырыла.

Актларга коррупциягә каршы экспертиза аларны куллануны мониторинглаганда, шулай ук Дәүләт комитеты хокукый актларында коррупциоген факторлар булу турында мәгълүмат Дәүләт комитетына кергән очракта уздырыла.

1.3. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләре яисә конфиденциаль характердагы белешмәләре булган актларга карата уздырылмый.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза үз көчен югалткан яисә юкка чыгарылган норматив хокукый актларга карата уздырылмый.

1.5. Дәүләт комитетында актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза оештыруның төп принциплары түбәндәгеләр була:

а) актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыруның мәҗбүрилеге;

б) актның башка норматив хокукый актлар белән үзара бәйләнешен бәяләү;

в) актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләренең нигезлелеге, объективлыгы һәм аларны тикшереп булу мөмкинлеге;

г) актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыручы затларның компетентлыгы;

д) Дәүләт комитетының, шулай ук аның вазыйфаи затларының актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздырганда граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлеге.

## 2. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җаваплы, Дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләп куелучы хокукый һәм кадрлар эше бүлегенең вазыйфаи заты тарафыннан (алга таба – җаваплы зат) уздырыла.

2.3. Хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә кергән актлар проектлары коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) (1 нче кушымта) кергән көнне үк теркәлә.

Җаваплы зат актларны куллану мониторингын уздырганда, шулай ук актларда коррупциоген факторлар барлыгы турында мәгълүмат алганда, Дәүләт комитеты актларында коррупциоген факторларны ачса, коррупциоген факторлар ачылган яисә актларда коррупциоген факторлар барлыгы турында мәгълүмат алган көнне үк аларны Журналга теркәп куя.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза Журналда акт проекты теркәлгән көннән биш эш көне эчендә уздырыла.

2.5. Актка һәм акт проектына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча җаваплы зат тарафыннан бәяләмә әзерләнә һәм имзалана.

2.6. Актта һәм акт проектында коррупциоген факторлар ачылганда коррупциоген факторлар булу турындагы бәяләмәдә (2 нче кушымта) коррупциоген факторлар чагылдырыла һәм аларны бетерү алымнары тәкъдим ителә.

2.7. Акт әзерләүче структур бүлекчә ачылган коррупциоген факторларны бетерү максатында өч эш көне эчендә үзгәрешләр кертү турында Дәүләт комитеты акты проектын йә актның үз көчен югалтуын тану турында проект әзерли һәм аны хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

Акт проектны әзерләүче структур бүлекчә өч эш көне эчендә кабат коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен аны хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә җибәрергә тиеш. Кабат коррупциягә каршы экспертиза өч эш көне эчендә уздырыла.

2.8. Актларда һәм актлар проектларында коррупциоген факторлар булмаган очракта, коррупциоген факторлар булмау турында бәяләмә рәсмиләштерелә (3 нче кушымта), ул акт проектын әзерләүчегә җибәрелә.

2.9. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылдырыла.

2.10. Дәүләт комитеты рәисе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә коррупциягә каршы экспертизага карата актны (акт проектын) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә хокуклы.

## 3. Актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру

3.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары Дәүләт комитетының рәсми бастырып чыгарылган һәм Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнә торган һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Дәүләт комитеты рәсми сайтында www.arhiv.tatarstan.ru (алга таба – сайт) урнаштырылган актлары һәм актлары проектлары була.

3.2. Дәүләт комитеты актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Дәүләт комитетының акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә карау өчен җибәргән көнгә туры килүче эш көне эчендә акт проектын архив тармагының мәгълүматлаштыру секторына җибәрә.

Архив тармагының мәгълүматлаштыру секторы акт проектын, эксперт бәяләмәләрне җибәрү өчен адресын (шул исәптән электрон почтасы адресын да), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итү башлану һәм тәмамлану датасын күрсәтеп, сайтта урнаштыра.

3.3. Сайтта урнаштырылган актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы кимендә биш эш көне булырга тиеш.

3.4. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим итү характерында була һәм Дәүләт комитеты тарафыннан һичшиксез каралырга тиеш. Бәяләмәне алган көннән соң 15 көнлек срокта Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе кергән бәяләмәне карый һәм дәлилләнгән җавапны коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырган юридик затка яисә физик затка җибәрә, моңа ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү алымы турындагы тәкъдим бәяләмәдә булмау очрагы керми.

3.5. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциоген факторлар Дәүләт комитетының актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе тарафыннан әлеге Тәртипнең 3.4 пунктында билгеләнгән срок эчендә бетерелә.

3.6. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кисәтүләрне бетергәннән һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң Дәүләт комитетының акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын кабат карау өчен хокукый һәм кадрлар эше бүлегенә, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне кушып, кабат карауга җибәрә. Кабат карау өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.7. Әгәр актта коррупциоген факторлар ачыкланса, Дәүләт комитетының әлеге актны әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе бәяләмә Дәүләт комитетында теркәлгән көннән өч көнлек срокта актка үзгәрешләр кертү буенча яисә аның үз көчен югалтуын тану турында чаралар күрә.

3.8. Дәүләт комитеты актларында һәм Дәүләт комитеты тарафыннан әзерләнгән актлар проектларында коррупциоген факторлар булуны таныклаучы коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, Дәүләт комитеты законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге актларны (актлар проектларын), коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең килешмәвен нигезләп,

аңлатма язуын кушып, коррупциягә каршы экспертизага дип Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрә.

---

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә
1 нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага кергән**
**норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу**
**журналы**

| № т/с | Актны (акт проектын) экспертизага кабул итү датасы | Актны (акт проектын) әзерләгән структур бүлекчә атамасы | Акт (акт проекты) атамасы | Экспертиза уздыру срогы | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Бәяләмә датасы һәм номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

Татарстан Республикасының Архив эше буенча
дәүләт комитетының норматив хокукый актларына
һәм норматив хокукый актлары проектларына
коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә
2 нче кушымта

**Коррупциоген факторлар булу турында бәяләмә**

№ ________ ____________

______________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге № 172-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге № 96 карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан

______________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

аңарда коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны киләчәктә бетерү максатларында коррупциягә каршы экспертиза уздырыла.

Тәкъдим ителгән

______________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

коррупциоген факторлар ачыкланган

______________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

(коррупциоген факторлар төрләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү алымнары күрсәтелә)

______________________ ______________________ __________

(вазыйфа атамасы) (инициаллары, фамилиясе) (датасы)

_________

(имзасы)

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә 3 нче кушымта

**Коррупциоген факторлар булмау турында бәяләмә**

№ _________ _______________

_______________________________________________________________________________

____________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге № 172-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге № 96 карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан

_______________________________________________________________________________

____________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

аңарда коррупциоген факторларны ачыклау һәм аларны киләчәктә бетерү максатларында коррупциягә каршы экспертиза уздырыла.

Тәкъдим ителгән

_______________________________________________________________________________

____________________________________________________________________

(норматив хокукый акт яисә норматив хокукый акт проекты атамасы)

коррупциоген факторлар ачыкланмады.

______________________ ________________________ ______________________

(вазыйфа атамасы) (инициаллары, фамилиясе) (датасы)

_________

(имзасы)